**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 4 сентябрендәге 3108 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты**
**карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын актуальләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге карарларын гамәлдән чыккан дип танырга:

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 ноябрендәге 3761 номерлы «Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчеләре эшчәнлеген тәэмин итү чараларын үткәрүгә Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карары;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 7 ноябрендәге 4645 номерлы «Тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директорлар киңәшчеләренә айлык акчалата түләү бирүгә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карары.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Руководитель** **Р.Г.Гафаров**